ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

12 март 2026 ел

№ 2325

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турындагы нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 маендагы 3673 номерлы Карары;

2) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 маендагы 3673 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 июлендәге 4596 номерлы Карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 12 мартындагы
2325 номерлы карарына
кушымта

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт (алга таба – Хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

2. Хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

Гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә гариза бирүче тарафыннан вәкаләтләнгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) якларга мөмкин.

3. Гариза бирүчегә Хезмәт «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) урнаштырыла торган гариза бирүченең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелергә тиеш.

## 2 бүлек. Хезмәт күрсәтү стандарты

### Хезмәтнең исеме

4. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, рөхсәтне гамәлдән чыгару.

### Хезмәт күрсәтүче органның исеме

5. Хезмәтне Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба — Башкарма комитет) күрсәтә.

### Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Гариза бирүче «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү» буенча мөрәҗәгать иткәндә, Хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып тора:

1) реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт (6 нчы кушымта);

2) Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (10 нчы кушымта);

7. Гариза бирүче «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару» буенча мөрәҗәгать иткәндә, Хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып тора:

1) реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару турында карар (11 нче кушымта);

2) Хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (10 нчы кушымта).

8. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, Башкарма комитет вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетына җибәрелә.

9. Гариза бирүченең сайлавы буенча, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән электрон документның кәгазьдә бастырып чыгарылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәренең имзасы белән расланган нөсхәсе формасында КФҮдә алынырга мөмкин.

10. Гариза бирүче хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен, электрон документ формасында яки электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә, Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

## Хезмәт күрсәтү срогы

11. Хезмәт күрсәтүнең максималь срогы, гариза бирүченең категориясенә (билгеләренә) һәм документларны тапшыру ысулына карамастан, 12 эш көне тәшкил итә.

Гариза һәм теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) КФҮ аша;

2) Бердәм портал, Республика порталы аша;

3) Башкарма комитетка.

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт биргәндә, хезмәт күрсәтү срогы 12 эш көне тәшкил итә;

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгарганда, хезмәт күрсәтү срогы – 7 эш көненнән артык түгел.

12. Хезмәт күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.

Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ формасында җибәрү Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

## Гаризаны һәм Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм Хезмәт күрсәтүне туктату яки Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

13. Түбәндәге нигезләр булганда, гаризаларны һәм Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет кабул итә:

1) Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән документларның тулы булмаган комплектын тапшыру;

2) законлы вәкилләр турында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган мәгълүматлар расланмау, гариза бирүче исеменнән гариза (запрос) аңа вәкаләт бирелмәгән зат тарафыннан бирелү;

3) документлар тиешле булмаган органга тапшырылу;

4) дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар, алдан килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңларга мөмкинлек бирми торган җитди кимчелекләр булган документлар, үз көчен югалткан документлар тапшырылу;

5) Хезмәт күрсәтү өчен, Регламент нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булып тормаган зат мөрәҗәгать итү;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булу;

7) электрон формадагы гариза (запрос) һәм башка документлар, гамәлдәге законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган;

8) электрон документлар аларны бирү форматларына карата таләпләргә туры килми һәм (яки) укылмый.

9) реклама конструкциясен урнаштыру күздә тотылган урында реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә гамәлдә булган рөхсәт булу.

14. Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.

15. «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү» хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет түбәндәге нигезләр буенча кабул итә:

1) ведомствоара запроска дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы буйсынуындагы оешманың хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавын таныклый торган җавабы керү;

2) реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми мөлкәтеннән файдалану күздә тотылган очракта, күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми тавышларыннан өчтән икесенең ризалыгы булмау;

3) гариза бирүче тарафыннан хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү факты расланмаган;

4) реклама конструкциясенең проекты һәм аны территориаль урнаштыру техник регламент таләпләренә туры килмәү;

5) билгеләнгән урында реклама конструкциясен урнаштыру реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасына туры килмәү («Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.8 өлеше нигезендә, реклама конструкцияләрен урнаштыру урыны реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы белән билгеләнгән очракта);

6) транспорт хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча норматив актлар таләпләрен бозу;

7) җирлекнең яки шәһәр округының тышкы архитектура күренешен бозу. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары яки шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тиешле муниципаль берәмлек территориясендә яки аның территориясенең бер өлешендә реклама конструкцияләренең типларын һәм төрләрен, шул исәптән, җирлекләрнең һәм шәһәр округларының барлыкка килгән төзелешләренең тышкы архитектура күренешен саклау кирәклеген исәпкә алып, мондый реклама конструкцияләренә карата таләпләрне билгеләргә хокуклы;

8) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), аларны саклау һәм куллану турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозу;

9) реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми мөлкәте файдаланылган очракта, 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5 өлешендә, 5.1, 5.6, 5.7 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрне бозу;

10) гариза бирүченең инициативасы буенча Хезмәт күрсәтүгә гаризаны кире алу.

16. «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару» Хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет түбәндәге нигезләр буенча кабул итә:

1) мондый рөхсәтне гамәлдән чыгару өчен мөрәҗәгать иткәндә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамлану;

2) гариза бирүченең инициативасы буенча Хезмәт күрсәтүгә гаризаны кире алу.

Хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме
һәм аны алу ысуллары

17. Дәүләт пошлинасы Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 статьясындагы 1 өлешенең 105 пунктында түбәндәге күләмдә каралган:

реклама конструкциясен урнаштыруга рөхсәт бирү өчен – 5000 сум.

Дәүләт пошлинасы гариза биргәнче түләнә.

18. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

19. Хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү гариза бирүче тарафыннанБердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, алдан тутырылган реквизитлар буенча гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләгәндә гариза бирүчегә тутырылган яки өлешчә тутырылган түләү документын саклау, шулай ук тутырылган түләү документының күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә.

Түләү документында исәпләүнең уникаль идентификаторы һәм түләүченең идентификаторы күрсәтелә.

Гариза бирүчегә Бердәм портал, Республика порталы аша Хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы фактын башкару турында хәбәр ителә.

20. Башкарма комитет гариза бирүчедән Хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслаучы документлар бирүне таләп итәргә хокуклы түгел.

Хезмәт күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы түләү турында мәгълүмат бирү, әгәр федераль законнарда башкача каралмаган булса, дәүләт һәм муниципаль түләүләр турындагы Дәүләт мәгълүмат системасында булган мәгълүматтан файдаланып гамәлгә ашырыла.

21. Дәүләт пошлинасы яки Хезмәт күрсәтү өчен алына торган башка түләү күләме турындагы мәгълүмат Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырыла.

Хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда
чиратта көтүнең максималь срогы

22. Хезмәттән файдалануга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

23. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел.

Гариза бирүченең Хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы

24. КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирелгән көнне гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы теркәү номеры һәм гариза бирү датасы белән КФҮ АМСтан өземтә бирелә.

25. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм портал, Республика порталының шәхси

кабинетында һәм электрон почта аша, теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән, гариза җибәрелүне раслаучы белдерү кәгазе ала.

26. Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, ике нөсхәдә гариза бирелгән көнне бер нөсхә, гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү датасын күрсәтеп, Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гариза бирүчегә кире кайтарыла.

## Хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр

27. Хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

28. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, Хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында тәэмин ителә:

1) инвалидларның хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (биналарга/биналардан уңайлы керү/чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү);

2) гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырылган Хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

5) аларның яшәеш мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алып, инвалидларның хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;

6) ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

7) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Юл күрсәтүче этне махсус өйрәтүне раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н Боерыгы белән билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, юл күрсәтүче этне кертү.

29. Инвалидлар өчен Хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга керү һәм Регламентның 23 пунктының 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән Хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган чаралардан файдалануны тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

30. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр турындагы мәгълүмат Башкарма комитетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырыла.

## Хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре

31. Хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып тора:

документларны кабул итү һәм бирү башкарыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләр булу;

мәгълүмат стендларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында Хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга хезмәтләрдән башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

32. Хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;

2) Хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга нигезле шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

- Хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең КФҮ хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

- КФҮдә Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазь нөсхәсе формасында алу кирәк булган очракта бер тапкыр.

Хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән бер хезмәттәшлек дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, Хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләргә хокуклы.

33. Хезмәтне гариза бирүчеләрнең ихтыяҗларына туры килүгә тикшерү Башкарма комитетның «Башкарма комитетта тышкы һәм эчке клиентлардан кире элемтәне җыю һәм анализлау тәртибен раслау турында» 2025 елның 11 августындагы 1803-р боерыгы белән билгеләнгән кире элемтәне анализлау нигезендә даими рәвештә үткәрелә.

Хезмәт күрсәтү процессларын оптимальләштерү гариза бирүчеләрнең Хезмәт күрсәтү процессыннан канәгатьлек дәрәҗәсе тотрыклы рәвештә кимегән (рәттән өч айдан артык) очракта үткәрелә.

Хезмәт күрсәтү процессыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимемәгән очракта, оптимальләштерү кимендә биш елга бер тапкыр үткәрелә.

34. Хезмәт күрсәтү барышы һәм статусы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында, КФҮдә алынырга мөмкин.

35. Хезмәт күрсәтү экстерриториаль принцип буенча, яшәү урынына яки фактта яшәү (тору) урынына бәйсез рәвештә, гариза бирүченең сайлавы буенча теләсә кайсы КФҮдә гамәлгә ашырыла.

36. Гариза бирүче Хезмәтне комплекслы запрос составында алырга мөмкин.

37. Хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре турында мәгълүмат Башкарма комиетның, КФҮнең рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырыла.

## Хезмәт күрсәтүгә карата башка таләпләр

38. Хезмәт электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче хокуклы:

1) Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, Хезмәт күрсәтү турында гариза һәм Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә элек электрон рәвешләре таныкланган документларны һәм мәгълүматны бирергә;

3) электрон формада бирелгән Хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы һәм статусы турында мәгълүматлар алырга;

4) Бердәм портал, Республика порталы аша Хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

39. Гаризаны формалаштыру, гаризаны нинди дә булса башка формада өстәмә рәвештә бирмичә, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

40. Гариза бирүчеләрнең КФҮгә кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Бердәм портал, Республика порталы, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчегә, күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә, кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге датага кадәр бер тәүлек алдан тәмамлана.

Бердәм портал, Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, гариза бирүчегә системада сорала торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләге буенча);

кабул итүне теләгән көн һәм вакыт.

Алдан язылу вакытында гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүматлар шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче тарафыннан бирелгән документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, гариза бирүчегә раслау талоны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан 15 минут узуга ул килмәгән очракта алдан язылу гамәлдән чыгарылу турында гариза бирүчегә мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Гариза бирүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы

дәвамлылыгын исәпләү өчен кирәкле мәгълүматлардан тыш, башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

41. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында, түбәндәгеләргә бүлеп, Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән:

1)«Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү» Хезмәтен күрсәтү өчен, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар;

2) «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәтне гамәлдән чыгару» Хезмәтен күрсәтү өчен, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы документлар.

42. Гариза һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның формалары турында мәгълүматлар әлеге Регламентка 5 нче, 7 нче, 8 нче кушымталарда китерелгән.

3 бүлек. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары

Административ процедуралар исемлеге

41. Хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) Хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документларны кабул итү;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

3) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) гариза бирүчегә Хезмәт нәтиҗәсен бирү.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек

44. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен «Бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати запросларны җибәрергә кирәк:

1) «Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан күчемсез милек объекты турында өземтә» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос, Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне эчендә, Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенә җибәрелә. Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара запрос җибәрелгән вакыттан башлап 2 эш көненнән артмаган срокта бирә;

2) «Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос, Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне эчендә, Федераль салым хезмәтенә җибәрелә. Федераль салым хезмәте соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара запрос җибәрелгән вакыттан башлап 5 эш көненнән артмаган срокта бирә. Запрос хезмәт күрсәтүне сорап юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла;

3) «Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә» мәгълүмати запросы. Күрсәтелгән мәгълүмати запрос, Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне эчендә, Федераль салым хезмәтенә җибәрелә. Федераль салым хезмәте соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара запрос җибәрелгән вакыттан башлап 5 эш көненнән артмаган срокта бирә. Запрос Хезмәт күрсәтүне сорап шәхси эшмәкәр мөрәҗәгать иткән очракта гамәлгә ашырыла.

45. Хезмәттән файдалану өчен башка сервислар ярдәмендә түбәндәге ведомствоара мәгълүмати запросларны җибәрергә кирәк:

1) «Гариза бирүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ» мәгълүмати запросы. Хезмәт күрсәтүне сорап гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, күрсәтелгән мәгълүмати запрос «Бердәм дәүләт гражданнар хәле актларын теркәү реестры» сервисы яисә «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә, 1 эш көненнән артмаган срокта тормышка ашырыла;

2) «Ышаныч язуы бирү факты һәм аның эчтәлеге турында мәгълүматлар» мәгълүмати запросы. Хезмәт күрсәтү буенча гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, күрсәтелгән мәгълүмати запрос «Бердәм нотариат мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә, 1 эш көненнән артмаган срокта тормышка ашырыла;

3) дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүматлар - дәүләт һәм муниципаль түләүләрнең дәүләт мәгълүмат системасы;

4) күчемсез милек хуҗасының әлеге мөлкәткә реклама конструкциясен тоташтыруга ризалыгын раслый торган документ («Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда (алга таба – 38-ФЗ номерлы Федераль закон), әгәр реклама конструкциясе тоташтырыла торган мөлкәткә ия булу һәм (яки) файдалану хокукын раслый торган документта мондый ризалык булмаса) – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы яки Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе;

5) 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.1 өлешендә билгеләнгән тәртиптә яки 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда төзелгән реклама конструкциясен урнаштыруга һәм тоташтыруга шартнамә (муниципаль милектәге объектта, дәүләт милке чикләнмәгән җир участогында, Татарстан Республикасы милкендәге һәм муниципаль район (шәһәр округы) территориясендә урнашкан җир участогында) – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы яки Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе);

6) реклама конструкциясе һәм аның территориаль урнашуы Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), аларны саклау һәм куллану турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү турында мәгълүматларны үз эченә алган документ (реклама конструкциясен Бердәм дәүләт Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) реестрына кертелгән мәдәни мирас объектында (тарихи һәм мәдәни ядкәрдә) урнаштырган очракта) – мәдәни мирас объекты буларак ачыкланган федераль, региональ әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары өчен мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты, җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары өчен муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитеты;

7) Бердәм дәүләт Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) реестрыннан мәгълүматлар – Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты;

8) җир участогы бирү өчен чикләүләр булу турында яки булмау турында (шул исәптән территориаль зона, кызыл линия чикләре, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар булу турында) бәяләмә - Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (МКУ, бүлек);

9) ышаныч язуы бирү факты һәм аның эчтәлеге турында мәгълүматлар - бердәм нотариат мәгълүмат системасы.

## 4 бүлек. Хезмәт күрсәтү турындагы запросны карап тикшерү статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

46. Гариза бирүчегә, аның хезмәт күрсәтүгә запросының Регламентта билгеләнгән статусы үзгәрү турында (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карап тикшерү турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү турында), шулай ук гариза бирүченең хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән этабында башкарырга тиешле адымнары һәм гамәлләре турында, техник мөмкинлек булганда, түбәндә санап үтелгән ысулларның берсе ярдәмендә хәбәр ителә:

